| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 14 декабре № 23/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендәге Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Советының 2022
елның 14 декабрендәге
23/1 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1) 7 статьяның 1 пунктында:**

түбәндәге эчтәлекле **7.1 пунктча өстәргә:**

«7.1) авыл торак пунктлары читендәге район чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;»;

**32 пунктчада** «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

**2) $7^1$ статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле **19 пунктча өстәргә:**

«19) муниципаль янгын сагын булдыру.»;

**3) 15 статьяда:**

**5 пунктны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«5. Күрсәтелгән гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.droganoye.tatarstan.ru) урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга тиеш (алга таба – Бердәм портал).

Бердәм порталда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкына хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар билгеләү һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат урнаштыру, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының шәхси кабинетын кулланып, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакытта Бердәм порталның кире элемтә платформасының (алга таба – органның шәхси кабинеты) тиешле бүлегендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы аппаратының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

**түбәндәге эчтәлекле 6.1** пункт өстәргә:

«6.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча гавами тыңлауларга чыгарылган үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган кисәтүләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы тарафыннан, авторизациядән соң, Бердәм портал кулланып, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүматны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы шулай ук үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.».

**9 пунктны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«9. Кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында басылып чыга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.droganoye.tatarstan.ru) һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

**4) 29 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Районның территориаль сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләп кую өчен кандидатура тәкъдим итү;»;

**5) 44 статьяда:**

**7 нче пунктчаны** түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- авыл торак пунктлары читендәге район чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.»;

**9 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«- муниципаль янгын сагын булдыру»;

**6) 53 статьяның 2 пункты** түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан вазыйфага билгеләнә.

Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы катнашында башкарыла. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының күрсәтелгән тикшерүне уздыруда катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче номерлы кушымта белән билгеләнә.»;

**7) 55 статьяны төшереп калдырырга;**

**8) 92 статьяның 7 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Район бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасы нигезләмәләренә;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезләмәләренә;

Россия Федерациясенең милли үсеше максатларының һәм халыкка ачык хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документларга;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләренә (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә);

социаль-икътисади үсеш фаразына;

озак сроклы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);

дәүләт (муниципаль) программаларына (дәүләт (муниципаль) программалары проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына).».

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы М.Р. Гафаров